| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2020 с.Старое Дрожжаное № 266

Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне вакытлыча туктатып тору чорында мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 5 ст., 9 ст. 1 п. 1ө. үтәү йөзеннән, мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне вакытлыча туктатып тору чорында мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы И.А. Халитовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Чүпрәле муниципаль
районының Башкарма
комитет карарына кушымта
"27" 05 2020 № 266

Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне вакытлыча туктатып тору чорында мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү
Тәртибе

1. Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең мәктәпкәчә белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибе (алга таба -Тәртип) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 5 ст., 9 ст. 1 п. 1 ө. нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын (алга таба - учреждениеләр) гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларын тәэмин итү максатларында эшләнгән.

2. Балаларны учреждениегә кабул итүне вакытлыча туктатып тору (алга таба-кабул итүне туктатып тору) Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча гамәлгә ашырыла (алга таба-гамәлгә куючы).

3. Кабул итүне туктатып торуның сәбәпләре: учреждениегә капиталь ремонт үткәрү вакыты, җәйге чор (бары тик авыл мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен генә), тәрбияләнүчеләрнең һәм персоналның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар, шулай ук гамәлгә куючы карары буенча башка сәбәпләр.

4. Кабул итү туктатыла:

- учреждениедә капиталь ремонт үткәрү чорында-гамәлгә куючының шәхси карары буенча;

- тәрбияләнүчеләрнең һәм персоналның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү чорында-Роспотребнадзор, янгын күзәтчелеге органнары белән килешенеп һ. б.;

- башка сәбәпләр барлыкка килгән очракта-тиешле структуралар, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү буенча (кирәк булганда).

5. Учреждение эше турында ата-аналар җыелышы карары җәйге чорда булырга тиеш:

- тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарының (законлы вәкилләренең) кабул итүне туктатып тору турында үтенече;

- тәрбияләнүчеләрне кабул итүне туктату вакыты турында мәгълүмат.

6. Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) ихтыяҗы булган очракта, учреждениедә тәрбияләнүчегә ата-ана (законлы вәкил) ризалыгы белән кабул итүне туктатып

торганда яки килеп туган очракта, кушымта нигезендә теләсә кайсы учреждениедә урын күрсәтелергә тиеш.

Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең вакытлыча туктатып тору чорында мәктәпкәчә белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү тәртибенә кушымта

Балаларны кабул итү вакытлыча туктатып торган чорда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен беркетү

| № | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең исеме | Адресы | Беркетелгән |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле 1 нче номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, 2-ая Пятилетка ур., 5 | «Зур Аксу «Ивушка» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Зур Чынлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Иске Шәйморза 1 нче номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Яңа Борындык башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Городище балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Матак балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Яңа Әлмәле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Иске Әлмәле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «Чуаш Бизнәсе башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Иске Дуван башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |
| 2 | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле 2 нче номерлы «Әкият» балалар бакчасы» | 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске | «Алешкин-Саплык «Теремкәй» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Кече Чынлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | Чүпрәле авылы, Зеленая урамы, 1Б | «Түбән Чәке «Кояшкай балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>«Иске Кәкерле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>«Чуаш Чүпрәлесе балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>«Шланга балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>«Марс балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>«Иске Чокалы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>«Татар Шатрашаны башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, |
| 3 | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Чүпрәле авылы, Яшьләр урамы, 17 | «Хорновар-Шигали балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>«Үби балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>«Кече Үби балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>«Яңа Үби балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>«Татар Бизнәсе башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>«Советлар Союзы герое Нурулла Гарифулла улы Фазлыев исемендәге Мунчали башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |

Эшләр идарәсе җитәкчесе Д.Р. Сабирҗанова